12+
DARELFONUN
УНИВЕРСИТЕТ
Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы
21 октябрь, 2016 ел
№ 6 (151)

### МӘГАРИФНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ

КФУ ректоры **И.Гафуров** «Глобаль университетлар» Ассоциациясе әгъзаларының гомуми җыелышы утырышында катнашты. Заманча дәүләт мәгарифенең киләчәге турында фикер алышуда вице-премьер **О.Голодец**, РФ Мәгариф һәм фән министры **О.Васильева** катнаштылар. Утырышта җиткерелгән төп фикер – дәүләт мәгарифен ныгыту һәм Россия университетлары алдында килеп туган каршылыкларны җиңү проблемасын камилләштерү юлында киртә була алмый.

### ХӨРМӘТЛЕ КОЛЛЕГАЛАР!

Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе һәм «Darelfønyn» газетасы редакциясе Сезне **Корпоратив гаммәви мәгълүмат чараларына багышланган фәнни-гамәли семинарда** катнашырга чакыра. Семинар 15 нче ноябрьдә булачак.

### МӘГЪЛҮМАТИ КЫР

Бүген Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбендә XIII **«Хәзерге Россиянең мәгълүмати кыры: гамәлләр һәм нәтиҗәләр»** Халыкара фәнни-гамәли конференция башланды. Россия төбәкләреннән һәм чит илдән 30дан артык кунак килде. Берничә секция эшли. Аларда журналистика тарихы, заманча журналистиканың бизнес, сәясәт, мәгърифәт белән бәйлелеге, медиабелем бирүнең актуаль мәсьәләләре каралачак. Кызыклы чыгышлар көтелә.




Лилия Туктарова фотосы

Синең кулда – яратып укый торган газетаңның тәүге юбилей саны. Бу санда «Darelfønyn» сер пәрдәсен ачарга булды. Газета синә тиз арада килеп ирешсен өчен аны кемнәр әзерли? Аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге нинди?
Без инде аякта нык басып торабыз! Мактанырлык уңышларыбыз, башкалар белән уртаклашырлык тәҗрибәбез, биш ел эчендә эшләнгән эшебезнең нәтиҗәсе бар. Камиллеккә, һәрвакыт үсешкә, яңалыкка омтылабыз!

# ТӘҮГЕ ЮБИЛЕЙ БЕЛӘН, «DARELFӨNYN» МӘКТӘБЕ!

**НӘСИМ АКМАЛ,** «ТАТАРСТАН» ДӘҮЛӘТ РАДИОСЫНЫҢ ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ РЕДАКЦИЯСЕ БАШ МӨХӘРРИРЕ:



Газетасыз журналист мылтыксыз солдатка тиң. Казан (Идел буе) федераль университетында журналистлар әзерләнсен дә, студентларга үз фикерләрен җиткерергә, каләмнәрен чарларга мәйдан булмасын ди инде?! Һәрхәлдә, федераль университетта татар телендә студентлар өчен әлеге газетаның чыгып килүе, үз укучысына барып ирешүе сөенечле. «Татарстан» радиосы да әлеге газетаның һәр санын укып, танышып бара. Газета ачкан күп кенә сәләтле яшьләр – Казан университеты студентлары – соңрак радиотапшырулар геройлары да булалар. Бу безнең өчен дә зур ярдәмлек. Туган көнегез котлы булсын! Әле газетаның 5 яшен генә түгел, ярты гасырлык 50 яшен дә бүгенгедәй уңышлар белән каршы алырга язсын!

**МИҢНАЗЫЙМ СӘФӘРОВ,** «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫ БАШ МӨХӘРРИРЕ, КФУ ЖУРНАЛИСТИКА ҺӘМ МЕДИАКОММУНИКАЦИЯ ЮГАРЫ МӘКТӘБЕ УКЫТУЧЫСЫ:



«Darelfønyn» газетасына карата фикеремне җиткерергә сорагач, иң элек хәтергә студент елларым, ул вакытта В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укыган чаклар килә. Үзебез дә студентлар өчен «Ленинчы» газетасы чыгара идек. Соңрак ул, «Мәгърифәт» дип исемләнеп, республикакүләм басма булды. Кулга диплом алып, «Татарстан яшьләре» газетасында эшли башлагач та, яшьләр белән эшләү бүлеген җитәкләдем. Бүген дә республикабызның төп басмасы – «Ватаным Татарстан» газетасына практикага килүче студентларның күбесе беренче курсларда «Darelfønyn» мәктәбен үтүчеләр. Шуңа күрә әлеге басма гади генә газета түгел, ә чын мәгънәсендә тормыш мәктәбе дә. Кечкенә юбилеегыз белән сезне, коллегалар! Каләмегез һәрвакыт үткен, күзегез үткер булсын!

**ВАСИЛ ГАРИФУЛЛИН,** КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ТАТАР ЖУРНАЛИСТИКАСЫ КАФЕДРАСЫ МӨДИРЕ, ПРОФЕССОР:

Студентларның яраткан басмасы «Darelfønyn» үзенең биш еллык түгәрәк бәйрәмен иҗади эзләнүләр, табышлар, уңышлар белән каршылый. Һәрвакыттагыча, укучылары белән тыгыз элемтәдә, аларның мәнфәгатьләрен яклап, алар өчен иң кызыклы һәм кирәкле темаларны күтәреп тора газета. Киң җәмәгатьчелек тә «Darelfønyn»не милли мәгълүмат кырыбыздагы бер уникаль күренеш буларак кабул итте, милли яшьләребезне әйдәп баручы лидерларның берсе буларак танып өлгерде. Биш яшьлек «сабый» гына түгел, тәмам җитлеккән, үз йөзе, юнәлеше булган җитди басма ул хәзер!

Соңгы елларда «Darelfønyn»нең төрле конкурс-фестивальләрдә катнашып танылуы, шул исәптән республикабыз журналистларының иң абруйлы бәйгеләреннән саналган «Бәллүр каләм» бәйгесендә җиңү яулавы – кечкенә генә тырыш коллективның уртак хезмәт җимеше.

«Darelfønyn» редакциясен милләтебез өчен журналист кадрлар әзерләүче үзәк буларак та яхшы беләбез. Казан (Идел буе) федераль университетының Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе студентлары, биредә даими практика узып, каләмнәрен чарлыйлар. Әлеге газета мәктәбен узган яшьләрнең кайберләре инде республикабызның эре редакцияләрендә уңышлы эшли, матур иҗат җимешләре белән куандыра. Монысы өчен газетага аерым рәхмәт әйтәсе килә!

«Darelfønyn»гә киләчәктә тагын да олырак юбилейларын каршыларга насыйп булсын! Бер яктан мәгариф, югары мәктәп тормышын, икенче яктан милләтебез яшәешен, яшьләр мохитен даими яктыртып баручы үзенчәлекле елъязма буларак, ул киләчәктә бай матбугатыбызның



мөһим бер сәхифәсе рәвешендә тарихта үз урынын алырга, тирән һәм кыю фикерле басма булып үсәргә тиеш! Иң мөһиме: яшәешебезнең иң четерекле мәсьәләләрендә дә газетаның какшамас үз позициясе булуы һәм аның үз укучысына һәрчак тугрылыклы хезмәт итүе зарур!

«Darelfønyn» газетасы коллективын истәлекле дата уңаеннан ихлас тәбрик итеп, аңа яңадан-яңа иҗади уңышлар, бетмәс-төкәнмәс иҗат дәрте, нәтиҗәле эшчәнлек һәм югары үрләр телибез!

# 10 ШӘҺӘР ДИКТАНТ ЯЗАЧАК!




29 ОКТЯБРЬДӘ «ТАТАРЧА ДИКТАНТ» АКЦИЯСЕ УЗАЧАК. АКЦИЯНЕҢ МАКСАТЫ – ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ХАТАСЫЗ ЯЗАРГА ӨЙРӘТҮ, ӘДӘБИ ТАТАР ТЕЛЕН КУЛЛАНУЧЫЛАР ДАИРӘСЕН АРТТЫРУ, ОРФОГРАФИК ҺӘМ ГРАММАТИК ХАТАЛАРНЫ ТИКШЕРҮ. ҺӘР ТЕЛӘГӘН КЕШЕ, ДИКТАНТ ЯЗУДА КАТНАШЫП, ТАТАР ТЕЛЕН БЕЛҮ ДӘРӘҖӘСЕН ТИКШЕРЕП КАРЫЙ АЛА.

Бүгенге көндә безнең алда татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтү мәсьәләсе тора. Соңгы вакытта Татарстан Республикасының төрле өлкәләрендә барган мөһим үзгәрешләр Татарстанның дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклаугa мөмкинлек бирә. Татар теле үсеше өчен шартлар тудырыла, татар халкының тарихына, мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә, традицияләренә кызыксыну арта. Шулай да, татар телендә сөйләшү проблемасы бүген дә актуаль.

Акция 29 октябрь көнне сәгать 11:00 дә бер үк көнне һәм бер үк вакытта Татарстанда, Россиянең төрле төбәкләрендә, шулай ук Казахстан һәм Кыргызстан шәһәрләрендә башланачак. Катнашучылар, татар теленнән орфографик һәм грамматик хаталарын тикшерер өчен, татар әдәбиятының классик язучысы Әмирхан Еникинең «Җиз кыңгырау» әсәреннән өзек язачаклар. Татар теленнән диктантларны күренекле тел белгечләре, профессорлар һәм филология фәннәре докторлары тикшерәчәк. Белем бирү акциясенең һәр мәйданында диктант текстын атказанган сәнгать эшлеклеләре, язучылар һәм танылган алып баручылар укыячак.

Казанда «Татарча диктант» Казан федераль университетының Л.Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында узачак (Татарстан ур., 2 йорт, 3 кат, актлар залы). Диктант текстын Татарстан Республикасының атказанган артисты, Г.Камал театры актеры **Фәнис Җиһанша** укыячак.

Һәр теләгән кеше, диктант язуда катнашып, татар телен белү дәрәҗәсен сынап карый ала. Теркәлү ***diktant.tatar*** сылтамасы аша.

Акцияне оештыручылар – Бөтендөнья татар яшьләре форумы, КФУның Л.Толстой ис. Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, «Каюм Насыйри институты» фәнни-белем үзәге, Бөтендөнья татар конгрессы, ТРның яшьләр һәм спорт министрлыгы.

• Безгә 5 яшь!

# БЕЗНЕ ТЫҢЛАГЫЗ, КАРАГЫЗ, УКЫГЫЗ!

**«Darelfөnүn»** газетасының иҗат төркеме «Татарстан» Дәүләт радиосының **«Яшьлек аланы»** һәм «Татарстан-Яңа гасыр» телевидениесенең **«Манзара»** тапшыруында кунакта булды. 20 нче октябрь – пәнҗешәмбе көнне 10 сәгать 35 минутта Казанда 99.2 FM ешлыгында чыккан әңгәмәнең радиодагы язмасын *radiotatarstana.ru* сайтында тыңлый аласыз. Кунаклар тыңлаучыларны газетаның уңышлары, килеп чыгышы, аны чыгару эше белән таныштырдылар. Ә «Татарстан-Яңа гасыр» телевидениесенең «Манзара» тапшыруын 21 нче октябрьдә иртәнге 6 дан алып 8 сәгать аралыгында күрә алачаксыз. Тапшыруның кабатлануы «ТНВ-Планета» телеканалында шул ук көнне 16.00-18.00 сәгать аралыгында булачак. Газетаның баш мөхәррир вазифаларын башкаручы **Ләйлә Сабирова** һәм хәбәрче **Айгөл Абдрахманова**, алып баручылар **Миләүшә Сибгатуллина** һәм **Илдар Кыямов** сезне «Darelfөnүn» газетасы эшчәнлеге, аның коллективы, укучылары, яңалыклары белән таныштырачаклар.





Ләйлә Сабирова фотолары

# ГӨРЛӘП ЯШӘГЕЗ!

Айгөл АБДРАХМАНОВА

ОКТЯБРЬ ИСТӘЛЕКЛЕ ВАКЫЙГАЛАРГА БАЙ. БЕЗНЕҢ ӨЧЕН БУ АЙ БИГРӘК ТӘ МӨҺИМ ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ. ШУЛ УҢАЙДАН БЕЗ РЕДАКЦИЯБЕЗГӘ НИГЕЗ САЛГАН КЕШЕЛӘРНЕҢ БЕРСЕ, ГАЗЕТАНЫҢ БЕРЕНЧЕ МӨХӘРРИРЕ – ХАННАНОВ РАМИЛ ГОМӘР УЛЫ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ КОРЫРГА БУЛДЫК.




**– Газетаның барлыкка килү тарихы нинди?**

– Бүгенге «Darelfөnүn» газетасы моннан нәкъ 10 ел элек – 2006 елның 24 октябрендә «Яшьлек тавышы» дигән исем астында беренче тапкыр дөнья күрде. Бу – университетта татарча профессиональ кимәлдә чыккан иң беренче студентлар газетасы. «Яшьлек тавышы» Самара шәһәрендә рәсми басма буларак теркәлде һәм, шул көннән башлап, ике атнага бер тапкыр басыла башлады. Газетаның иң беренче ике саны, «Мәгърифәт» газетасының кушымтасы булып, бөтен татар дөньясына таралды. Өченче саннан алып, газетаны чыгару һәм тарату эшен үзебез генә башкардык.

**– «Darelfөnүn» – «Яшьлек тавышы»ның башында кемнәр торды?**

– Газета тулысынча студентлар инициативасы белән эшләнде. Баш мөхәррир вазифасын мин башкардым, Рәйсә Гарипова газетаны версткага салды, Ләйлә Шакирова, Зөһрә Садретдинова, Айгөл Мөгыйнева, Нияз Сабирҗанов, Руслан Хөснетдинов, Илдар Сафиуллиннар корреспондент булып эшләделәр. Күбесе бүгенге көндә дә журналист хезмәтен дәвам итәләр, ТНВ каналында төрле тапшырулар алып баралар. Соңрак КФУның Яр Чаллы филиалында укучы студент кызлар һәм егетләр безгә килеп кушылдылар. Алар арасында Динара Әхмәтова (соңрак мине алыштырды), Рүзәл Мөхәммәтшиннар да бар иде. Газетада эшләүчеләргә өстәмә түләү каралмаган иде, барысы да студентларның үз теләкләре һәм үз көчләре белән эшләнде.

**– «Яшьлек тавышы». Ни өчен шундый исем бирергә булдыгыз?**

– Газетаның исеме бик тарихи. Сугыштан соңгы елларда Гөлшат Зәйнашева, Илдар Юзеев, Марс Шабаев, Лена Шагыйрьҗаннар педагогика институтында «Яшьлек тавышы» дигән альманах чыгаралар. Культязма җыентык тулысынча әдәбиятка багышлана, шул вакытта иҗат иткән яшь язучыларның әсәрләрен туплаган була. Бездә, газета булдыру идеясе белән бергә, нинди исем бирәбез, дигән сорау да барлыкка килде. Бу сорау белән Фоат Галимуллинга мөрәҗәгать иттек. Нәкъ менә Фоат абый газетага «Яшьлек тавышы» исеме бирергә тәкъдим итте. Моннан 5 ел элек газета өчен махсус штатлар ачылды, һәм без КФУ газетасына әйләндек. «Яшьлек тавышы» исемен элеккеге ТДГПУ студентлары һәм җитәкчелеге үзләренә калдыруны сорадылар, махсус студентлар газетасы булдырабыз диделәр. Кызганыч, әлеге газета оешып эшләп китә алмады. Ә безнең алга газетага яңа исем бирү мәсьәләсе килеп басты. Киңәшмә вакытында, шаяртып кына, русча «университет» булгач, татарча «darelfөnүn» (фарсы теленнән — университет) була, дигән идек, җитәкчелек бу фикерне җитди кабул итеп, газетага «Darelfөnүn» исеме бирелде.

**– Газетаны башлап җибәргәндә, нинди авырлыклар булды?**

– Яңа эш башлаганда, авырлыклар бик күп була инде. Шул ук техника мәсьәләсе: ул вакытта компьютерлар һәркемнең өендә юк, шуңа күрә студентлар мәкаләләрен кулдан язып килеп, дәресләрдән соң редакциягә кереп, компьютерда бастыралар, чират көтеп торалар иде. Компьютерларның «очкан», әзер материалларның югалган чаклары да аз булмады. Верстка өчен җавап биргән Рәйсә Гарипованың махсус белеме юк иде, барысын да үзлектән өйрәнде. Аңа да җиңел булмагандыр. Авырлыклар булмый тормый. Иң мөһиме: бирешмәскә кирәк.

**– Газетаны киләчәктә нинди итеп күрәсез?**

– Студентлар, яшьләр газетасы ул һәрвакыт аерылып тора. Мәктәп бусагасыннан зур уку йортына аяк баскан кызга яки егеткә үзен күрсәтү мөмкинлеге кирәк. Ә бу – менә дигән юл. Мәктәп елларында ук иҗат белән мавыккан яшь каләм, олы иҗатка килеп кергәнче, адаптация үтә, мәркәз тормышына иялəшә. Студентлар газетасының булуы хыялый яшьлекнең шул чоры өчен әһәмиятле. Ул булырга һәм гөрләп эшләргә тиеш! Ә аның сәхифәләре, башисемнәре, бизәлеше өчен мин борчылмыйм. Шартлар тудырылса, сәләтле иҗатчылар безнең милләттә бихисап.

## Хәтер-хатирә:

**ЛӘЙЛӘ ХАРИСОВА (ШАКИРОВА):**

Күпләргә сәер тоелыр: мин газетаның һәр яңа санын ике куллап тотып, күзләремне йомып, рәхәтләнеп иснии идем!.. Үзеннең бер айлык хезмәтеңне әнә шулай тотып карау, зур горурлык белән башкаларга өләшеп йөрү, ничек кенә гадәти яңгырамасын, алга таба тагы да яхшырак мәкаләләр язарга, яңа кызыклы темалар эзләргә илһамландыра… Нәкъ менә шул илһам безгә үз вакытында тыныч кына агып торган студент тормышына зур яңалыклар кертергә көч биргәндер инде.

# ЯШӘСЕН ИҖАТ! ЯШӘСЕН «DARELFØNYN»!

**Динара МИННЕКАЕВА,** газетаның мөхәррире

КЕШЕ БӘХЕТЛЕ БУЛСЫН ӨЧЕН НӘРСӘ КИРӘК, ДИГӘН СОРАУГА ҺӘРКЕМ ҮЗЕНЧӘ ҖАВАП БИРӘ! АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ БИРГӘН ГОМЕР, СӘЛАМӘТЛЕК, ТЫНЫЧ ИМИН ТОРМЫШ, ТУЛЫ ГАИЛӘ, ИСӘН-САУ ТУГАННАР, БӘХЕТЛЕ БАЛАЛАР ЯНЫНА МИН ТАГЫН ҺӘР ИРТӘ САЕН СӨЕНЕП БАРЫРДАЙ ЭШНЕ ДӘ КЕРТЕР ИДЕМ ӘЛЕ. АНДА СИНЕ КӨТЕП ТОРУЧЫ ХЕЗМӘТТӘШЛӘРЕҢ БУЛУ ДА – ЗУР БАЙЛЫК!

Минем хезмәт юлым мәктәптә укыганда ук башланды. Әнкәй, һәрьяктан да белемле булуыбызны теләп, бик күп газета-журналлар алдыра иде. Мин никтер шулар арасыннан «Мәгърифәт» газетасын сагынып көтә идем. Айга бер мәртәбә, аңа кушымта булып, педагогика университетында басыла башлаган «Яшьлек тавышы» газетасы килә иде. Бер хәрефен дә калдырмыйча укып чыга идем шуны. Шул югары уку йортына керү, андагы данлыклы галимнәрдән белем алу, төрле чараларда катнашу турында хыяллана идем. Ләкин язмыш мине шул университетның Чаллы филиалына укырга китерде. Бер ел дәвамында яңа дуслар, хөрмәтле остазларым барлыкка килде. Ул елларны бик сагынып искә алам… Әллә Казанда укырга теләү хыялы шулай нык булган, икенче елны филиалны башкалабыздагы төп вузга кушып куйдылар. Шулай итеп, мин гомерем буе хыялланган уку йортына килеп эләктем. Ул көннәрдә кичергән шатлыклы мизгелләрне сүз белән генә аңлатып бетереп булмый!



Влад Михневский фотосы

Укудан тыш та актив булды безнең төркем. Татар филологиясе факультетында «Раушан» гәҗитен чыгардык. «Илһам» әдәби-иҗат берләшмәсенә йөри башладык, каләмнәребез тагын да чарланды. Һәм мин бик уңышлы чыгып килә торган «Яшьлек тавышы» газетасына килдем. Әле кайчан гына чыга башлап, инде танылырга өлгергән газетаның киләчәк язмышында катнашу минем өчен зур дәрәҗә булды. Хөрмәтле укытучым — әлеге газетаның мөхәррире **Рамил Гомәр улы Ханнанов** чын журналист булуның серләренә төшендерде.

Уку йортларында үзгәрешләр булу сәбәпле, 2011 елның 6 октябрендә Казан федераль университеты базасында «Darelfønyn» газетасы чыга башлады. Беренче саннарын да Рамил абый җитәкчелегендә эшләдек. Состав бераз үзгәрсә дә, газетаның асылы һәм тагын бер мөһим кешесе — минем укытучым, басманың дизайны, ясалышы өчен җаваплы **Гөлфия Зилиф кызы Камалиева** үзгәрешсез калды. Ул бүген дә бу газета өчен җанын-тәнен биреп эшли, яңа идеяләр, кызыклы сәхифәләр белән баета, аның киләчәге өчен кайгыра.

> *«Darelfønyn» заман белән бергә атлый, һәр яңалыкны күтәреп ала белә, халыкка хезмәт итә»*

2013 елның гыйнвар аеннан газетада мөхәррир вазифасын миңа йөкләделәр. Коллективта яңа журналистлар, корректор, фотограф барлыкка килде. Безнең белән бергә шулай ук минем иң хөрмәтле укытучыларымның берсе — **Роза Әмин кызы Асылгәрәева** да эшли башлады. Роза апа белән без янәдән студент елларына кайткандай булдык. Телебезнең кагыйдәләрен искә төшердек, ул да безгә яңа идеяләр биреп, эшкә өйрәтте. Редакциядә төрле чаралар уздырдык. Безнең белән очрашуга республика мәктәпләреннән дә килделәр, газетабыз чит илләргә дә танылды. Читтә яшәүче милләттәшләребез даими хәбәрчеләребезгә әйләнде.

Бу чорда газетаның уңышлары да мактанырлык булды. Россия һәм республика күләмендәге конкурсларда иң югары бүләкләрне алдык, үзебезнең студентлар өчен кирәк булуыбызны дәлилләдек. Үз чиратымда, безгә һәрчак ярдәм кулы сузарга әзер булган, нинди генә сорау белән мөрәҗәгать итсәк тә ярдәм кулын сузган Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры **Рәдиф Җамалетдиновка**, аның җитәкчелегендә эшләүче һәр остазыма, татар журналистикасы кафедрасы мөдире **Васил Гарифуллинга**, студентларга искез-чиксез рәхмәтләремне җиткерәм.

Газетага да алга таба үсәргә, үзгәрергә кирәк. Күңелле вакыйгалар булу сәбәпле, мин әлегә «Darelfønyn»да мөхәррирлек итмим. Ләкин безгә алмашка күпкырлы шәхесләр — үз эшләренең осталары килде. Үз балабыздай якын газетаның шулай матур гына чыгуына чиксез шатланабыз. Ул заман белән бергә атлавын, укучыларын шатландыруын дәвам итә. Алга таба да озын гомерле, студентлар өчен кирәкле һәм файдалы булсын иде!

# Хәлбуки – ТАТАРЧА ЛЕКТОРИЙ

СИН ӨЕҢӘ КИЛГӘН ЭЛЕКТР ТОГЫНЫҢ ЧЫГАНАГЫН БЕЛӘСЕҢМЕ? Ә ДӨНЬЯДА ТОКМАЧКА ТАБЫНУЧЫЛАР БАРЛЫГЫН? ҺӘМ БАРЫБЫЗГА ДА ШУНДЫЙ ГАДӘТИ ҺӘМ ТАНЫШ КЕБЕК БУЛГАН СУЫТКЫЧ НИЧЕК ЭШЛИ ИКӘНЛЕГЕ СИҢА ТАНЫШМЫ? «ГЫЙЛЕМ» ПРОЕКТЫН СӨЮЧЕЛӘР БУ СОРАУЛАРГА ИНДЕ ҖАВАП ТАПТЫ! ЮК, БУ ЮЛЫ МӘКАЛӘЛӘРДӘН ГЕНӘ УКЫП ТҮГЕЛ, Ә ЧЫН МӘГЪНӘСЕНДӘ ЛЕКТОРИЙДАН!

**Эльвира ЗИННӘТУЛЛИНА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты



Туган телебездә фәннең серле дөньясын актырта торган «Гыйлем» проекты эшен яңа юнәлештә башлап җибәрде! Бу атнада проектның фәнгә гашыйк җитәкчеләре тәүге лекторий уздырды. «Милләт йорты»нда үткәрелгән чара **Азат Миргаязовның** (*фотода*) «Электр кайда туа һәм кайда үлә» темасы белән башланды. Тема кысаларында йорт җиһазларының эшләү принциплары белән таныштык. Икенче лекция дин белеменә кагылышлы булды: «Инквизиторлар һәм токмачка табынучылар: дин белгече нәрсәләр өйрәнә?» мәсьәләсенә багышланган иде. Дөньяда нинди диннәр бар, аларның килеп чыгышы турында һәм башка күп кенә кызыклы мәгълүматларны тыңлаучыларга **Айдар Шәйхин** җиткерде. Йомгак лекция шулай ук физика фәненә кагылышлы иде. Монда «Гыйлем» проектының якын дусты һәм киңәшчесе, Казанның 7 нче номерлы лицей-интернат укытучысы **Ренат Миргаязов** физика фәне белән көнкүрештә адым саен очрашып торуын ассызыклады.

Катлаулы фән турында гади тел белән сөйләп һәм кызыклы мисаллар ярдәмендә лекторлар тыңлаучыларның игътибарын яуладылар. Энә кайчан суда батмый? Чәйне электр чәйнегендә яки газ өстендә кайнату икътисади яктан кайсы отышлырак? Лекторийга килгәннәргә әлеге һәм башка бихисап кызыклы сорауларга җавап табу мөмкинлеге ачылды. Чараның нинди хисләр тудырганлыгы турындагы фикерләре белән лекцияләрне тыңлаучылар да бүлеште.

– Физика һәм химиядән мәктәп программасын бүген кабат искә төшердем. Фәнгә яңа караш ачты лекторий. Сөйләүчеләр үз өлкәләрен яхшы беләләр. Шуңа тыңлаучыны да җәлеп итә алдылар. Темалар да кызыклы. Яңаларын көтеп калам! – диде КФУ Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе студенты Гүзәлия Гыйниятуллина.

– «Гыйлем» һәрвакыт кызыклы проектлар тәкъдим итә. Шундый көттем бүгенге лекторийны! Мин, мәктәптә укыганда, үземә гел сорау бирә идем: нәрсәгә миңа бу физика дип. Әллә юлны физика формулаларын чишеп чыгасы буламы? Университетны бетергәндә, физикага да башкача карый башладым... Лекторийда мин, беренчедән, хатын-кыз буларак, икенчедән, филолог буларак, төрле атомнарны башымда үземчә тоташтырып утырдым! Мәсәлән, берәр әсәр язсам, хисләр темасына кереп киткәндә, ике җан иясе арасында туган көчле теләк хисен «кысылган молекулалар» итеп бирер идем! Вольфрам шикелле яндырып та була әле, ә сценарий азагында фреон шикелле геройның берсен суытып та куяр идем! – диде лекция тыңлаучыларның берсе.

*«Мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын»*
Габдулла Тукай

Менә шулай гаҗәеп кызыклы һәм җылы атмосферада үтте «Гыйлем»нең беренче лекцияләре. Белми, килә алмый калгансыз икән, бу борчылуга бер дә сәбәп түгел! Лекторийлар әле киләчәктә үткәреләчәк дип көтелә. Туган телдә фәннең серле дөньсына төшенәсең, яңа белемнәр туплыйсың килә икән, рәхим ит!

Киләсе лекторийлар турында мәгълүматны «Хәлбуки | Гыйлем. Лекторийлар» һәм «Гыйлем|татарча фәнфәһем» ВКонтакте төркемнәрендә таба аласың!



Автор фотолары

**Безне котлыйлар**

# ИҖАДИ ДУСЛАР



*«Darelfønyn» газетасы белән без һәрдаим хезмәттәшлек итәбез. Үткәргән чараларны газета яктыртып бара. «Darelfønyn» безнең аша Россия төбәкләренә һәм чит илләргә барып ирешә. Бүген, Казан университетын тәмамлап, читтә яшәүче татар студентлары аны көтеп алалар. Еракта яшәп тә, күңелләренә якын булган югары уку йортларында барган үзгәрешләр, бүгенге студентларның кызыксынулары, шөгыльләре белән танышып бару, үзләрен укыткан галимнәр турында мәгълүмат алу туган илдән килгән җылы хат кебек кабул ителә. Бу изге эшегездә алга таба да уңышлар сезгә, «Darelfønyn»челәр!*

**Бөтендөнья татар яшьләре форумы**



*Җиде дистәдән артык тарихы булган «Әллүки» әдәби иҗат берләшмәсе һәм «Darelfønyn» студентлар газетасы 5 ел янәшә атлыйлар. Чәчәк атып кына килүенә карамастан, «Darelfønyn» газетасы күпләребез өчен әдәби мәктәп, уку йорты булды һәм һәрдаим булып килә. Ул басыла башлаган көннән үк, уку йортыбыз студентлары, фәнни хезмәткәрләре газетада яңа аралашу кыры тапты. «Darelfønyn» ул – яңа сәләтләргә ачылырга, иҗади уңышларыбыз белән бүлешергә, яңалыклар белән саф әдәби татар телендә танышырга мөмкинлек бирә торган гаммәви мәгълүмат чараларының берсе. Без, «Әллүки»че татар яшьләре, «Darelfønyn»гә кызыклы һәм сыйфатлы язмалар белән даими сөендерүләрен, озын-озак гомер, күп санлы сәхифәләр, хезмәткәрләренә уңышлар телән калабыз. Туган көнең белән, «Darelfønyn»!*

**«Әллүки» әдәби иҗат берләшмәсе**

**Student's blok**



# Әгәр мин...

СТУДЕНТ ХАЛКЫНЫҢ ҺӘРБЕР КӨНЕ НИНДИ ДӘ БУЛСА МАҖАРАДАН ТОРА. КЫЗЫГЫ ДА, КЫЗГАНЫЧЫ ДА – ТӨРЛЕСЕ БУЛА. КЫЗЫКЛЫ ДӘРЕСЛӘР ТЫҢЛАРГА, ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ БИРЕМНӘР ҮТӘРГӘ ТУРЫ КИЛӘ.

**Фәнүзә СИРАҖИЕВА,** Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе

Безгә укытучыбыз Гөлназ Фоат кызы Гайнуллина үзенчәлекле бирем эшләп килергә кушты: «Әгәр мин...» дип аталган, һәрбер җөмләсе кереш сүздән башланган текст төзү. Башта бу безне борчуга салды. Ничек кенә башкарып чыгарга? Ләкин без озак баш ватмадык, киләсе парга күбебезнең әзер язмалары өстәл өстендә ята иде.

«Әгәр мин депутат булсам, сәясәт өлкәсенә зур өлеш кертергә тырышыр идем. Әлбәттә, депутат булу җиңел эш түгел, әмма мин, мөгаен, бу эшне башкарып чыга алыр идем. Әти-әнием уйлавынча, минем урыным нәкъ менә Дәүләт Думасында. Чөнки кечкенәдән яңа кануннар уйлап чыгарырга ярата идем. Мәсәлән, кем соңрак ашап бетерә, шул савыт-саба юа. Дөрес, хәзер мин үзгәрдем, үстем, фикерләвем дә башкачарак. Димәк, җәмгыятькә дә карашым икенче. Һичшиксез, үзем студент кеше буларак, берьюлы биш пар укытмаска дигән канун кабул итәр идем. Сүз уңаеннан, шулай ук студентларны пар бетәргә 5-10 минут кала чыгарырга дигәнен дә өстәр идем. Югыйсә, алар ял итеп өлгермиләр, тәнәфесләре ун минут кына. Икенчедән, һәйбер югары уку йорты студентлары әлеге дә баягы ун минутны бер бинадан икенчесенә баруга сарыф итә. Шул уңайдан, студентларның күбесе ашап өлгерми, ач кала. Минемчә, бу мәсьәләне кайгырту бик мөһим. Һичьюгы, һәрбер югары уку йортында ашханәләр булдырырга кирәк. Хәер, уку биналарында парольсыз вайфай куйдыру дигән фикер дә яшәп килә үземдә. Димәк, нәтиҗә ясап, шуны әйтә алам: миңа студентлар депутаты итеп сайлану кулай булыр иде. Әлбәттә, бу бик кызык яңгырый. Ләкин, студентларның күп кенә проблемаларын хәл итәргә булышыр идем. Шулай итеп, Дәүләт Думасына депутатлыкка барам, җәмәгать!»

# «Darelfonyn»чә ревиззоро

Лилия ТУКТАРОВА, Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе

**СТУДЕНТ ҮЗ ВАКЫТЫНЫҢ БЕР ӨЛЕШЕН АШХАНӘ, КАФЕ, БУФЕТЛАРДА ҮТКӘРӘ. ЯШЬ ВАКЫТТА НӘРСӘ АШАГАНЫҢНЫ, НИ БЕЛӘН ТУКЛАНГАНЫҢНЫ СИЗМИ ДӘ КАЛАСЫҢ. КФУ ИНСТИТУТЛАРЫ АШХАНӘЛӘРЕНДӘ НИЧӘ СУМГА ҺӘМ НӘРСӘ БЕЛӘН ТУКЛАНЫП БУЛУЫН ТИКШЕРЕП ЧЫКТЫМ.**


Редакция фотосы

Икенче пардан соң ашыйсы килә башлый инде. Ярар, монысында шоколад кына алып торыйм дисең дә, тагын бер пардан соң берәр буфетка чабасың. Дүртенче пардан соң инде син КФУ ашханәсендә яки урам кафесында. Дәресләр арасында вакыт тыгыз. Кайвакыт буфет ризыгы түгел, хәтта үзең белән алып килгәнең дә ашалмыйча кала.

Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының цоколь катында урнашкан «Трали-вали» кафесында тукланып чыгарга булдым. Хезмәт күрсәтүче персонал бик мөлаем татар апалары булып чыкты. Менә монысы шундый ризык, ә менә монысы фәлән бәягә төшә дип аңлатып та бирделәр.

• **СТУДЕНТЛАР ФИКЕРЕ**

Әйе, бу кафеда туклану безгә бик ошый. Ризыклар өйдә әзерләнгән сыман. Төрле татлы әйберләр дә бар. Бәяләр безнең кесәгә артык сукмый. Кайбер көннәрне монда аеруча тәмле кыздырылган бәрәңге (картошка-фри) була. Аны тиз арада алып бетерәләр. Шулай да ике минус бар. Беренчесе – ике кассадан берсе генә эшли. Шуңа чират җыела, дәрескә соңга калабыз. Икенче минус – залда еш кына ризык пешкәннән-көйгәннән тараллган начар ис була.

✓ *Бәя бирү*

– Кафе директоры әйтүенчә, ит ризыклары хәләл. Әмма студентлар ышанып бетми.

– Төшке аш бәясе уртача 120-150 сумга төшә: аш, бәрәңге боламыгы белән котлет, салат һәм компот. Бер телем ипи һәм берәр камыр ризыгы.

– Институтның өченче катында буфет бар. Анда, әйтүләренчә, ит ризыклары хәләл түгел.

Идарә, икътисад һәм финанслар институты ашханәсендә исә «Бездә дуңгыз ите юк», – дип каршы алдылар. Ашханәгә төшке аш вакытында килеп кердем. Залда барлыгы 5-6 студент ашап утыра. Кассага чиратта торучы күренмәде.

• **СТУДЕНТЛАР ФИКЕРЕ**

Күбесенчә без бу ашханәдә тукланмыйбыз, урам кафесына чыгып керәбез. Үзебезнең ашханә турында нәрсә әйтә алабыз: монда беркайчан да начар ис булмый, чиратлар юк. Тәмле пешерәләр, утырырга урыннар бар.

✓ *Бәя бирү*

– Ит ризыклары хәләл түгел.

– Төшке аш бәясе уртача 140 сум: фрикаделька белән токмачлы аш, бәрәңге боламыгы белән тавык котлеты, бер телем ипи һәм чәй.

– Институтта ризык сата торган ике киоск бар. Аларда да ит ризыклары хәләл түгел.

Икенче корпустагы буфетта сатучы ападан «Хәләлме?» дип сорагач, «Өчпочмакны белмим, ләкин камырдагы сосиска хәләл», – дип җавап бирде.

Икенче корпусның икенче катында кафе бар. Шулай ук төшке аш вакытына туры килдем. Кафеда барлыгы өч кеше ашап утыра иде. Пешерүче апалар итнең хәләл түгеллеген, ләкин дуңгыз ите юк икәнен төгәл әйттеләр.

• **СТУДЕНТЛАР ФИКЕРЕ**

Кафеда ашау безгә ошый. Монда чират зур түгел. Булса да, тиз бара, диделәр. Кафеда аз гына ис бар барлыкка. Пешерүчеләр һәрбер ризык турында аңлатып бирәләр. Утырырга урыннар җитәрлек.

✓ *Бәя бирү*

– Ит ризыклары хәләл түгел.

– Төшке ашның бәясе уртача 120 сум: макарон белән тавык котлеты, кәбестә ашы, чәй һәм ипи.

Физика институты ашханәсе турында миңа студентлардан күп ишетергә туры килде. Икенче курска җитеп, мин анда беренче тапкыр бардым. Ашханәләрнең икесе дә иркен һәм бик матур. Барлыгы 5-6 студент күренә. Урыннар һәркемгә дә җитәрлек.

• **СТУДЕНТЛАР ФИКЕРЕ**

Безгә монда туклану ошап бетми. Беренчедән, монда ис бар. Ул беркайчан да бетмәс, ахрысы. Кайчагында искиткеч тәмле ризыклар белән сыйлыйлар, тик шул ис аркасында берни алмыйча борылып чыгып китәбез. Монда безгә иң ошаганы – иркенлек. Әмма кайбер вакытта чисталык җитеп бетми дип саныйбыз.

✓ *Бәя бирү*

– Ит ризыклары хәләл түгел.

– Төшке аш бәясе уртача 140 сум: карабодай белән тавык котлеты, кәбестә салаты, чәй һәм ипи.

**НӘТИҖӘ:**

КФУ ашханәләрендә урыннар һәркемгә дә җитәрлек. Чират торучылар күренми. Ләкин ит ризыклары күбесендә хәләл түгел. Әмма дуңгыз ите юк дип ышандырдылар. Кайсы ашханәдә тукланырга икәнне һәр студент үзенчә сайлый булып чыкты: кем өчендер чисталык беренче чиратта, ә кем өчендер тәмлелек әһәмиятлерәк…

12+
DARELFONUN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: Р.Р.Садретдинов, А.А.Абдрахманова
Корректор - Р.Ә.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 334 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru
Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2016 елның 08 сентябрендә ПИ № ТУ 16-01506 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00, 20.10.2016. «Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.